# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**17 ноябрь 2025 ел** **№2**

2025 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы Уразай
авыл җирлеге Уразай торак пунктында
гражданнардан үзара салым кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законыңц 35 статьясы нигезендә
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1.2026 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә мобилизациялэнгэннэрнен гаилэ эгъзаларыннан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 200 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урам яктырткычларындагы лампаларны алмаштыру, яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Садовая,Н.Бэдертдинова урамнары шартнамәсе буенча вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу, эшләр өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (чүп үләнен чаптыру, чүп җыю, балалар мәйданчыкларын, ял итү зоналарын карап тоту, автомобиль юлын кардан чистарту, трактор өчен роторлы чапкыч сатып алу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Уразай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

(http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы ____________ Д.И.Мутыгуллина
Уразай авыл җирлеге башлыгы (имза) (имза расшифровкасы)